Карар № 74

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы
Кышлау авыл җирлеге Советы

Кышлау авылы 13 апрель 2023 ел

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Кышлау авыл җирлеге Советының 2012 елның 20 июнендә 38 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Кышлау авыл җирлеге муниципаль хезмәте турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында

2022 елның 5 декабрендәге 498-ФЗ номерлы «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында»гы Федераль закон нигезендә, Әтнә районы прокуратурасының 2023 елның 31 гыйнварындагы 02-08-02-2023 номерлы протестын карап чыгып, Кышлау авыл җирлеге Советы карар чыгарды:

1. Кышлау авыл җирлеге Советының 20.06.2012 ел, 38 нче номерлы карары белән
расланган "Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Кышлау авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәгә" (Советның 28.02.2013 №55, 24.02.2014 №71, 27.04.2015 №110, 18.03.2016 №21, 15.03.2017 №40, 20.07.2017 №50, 12.03.2018 №65, 20.07.2018 №72, 21.11.2018 №79, 22.04.2019 №91, 26.08.2019 №98, 20.01.2020 №117, 30.10.2020 №5, 21.07.2021 №34, 18.02.2022 №44 карары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 11 нче бүлекнең 11.1 пунктын түбәндәге эчтәлектәге 11 нче пункт белән тулыландырырга:
"11) аның чит ил агенты статусын алуы."

1.2. 26 нчы бүлекнең 26.1 пунктын түбәндәге эчтәлектәге 5 нче пункт белән тулыландырырга:
"5) муниципаль хезмәткәрнең чит ил агенты статусын алуы».

2. Әлеге карарны Әтнә муниципаль районының рәсми сайтында интернет челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru веб–адресы буенча һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында: pravo.tatarstan.ru веб–адресы буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җавапчылыгымда калдырам.

Әтнә муниципаль районы
Кышлау авыл җирлеге башлыгы А.Х.Кашшапов